Раслыйм: ____________
Әтнә районы Башкарма
комитетының "Мәгариф бүлеге"
казна учреждениесе җитәкчесе
Р.Р.Фатыхов

Габдулла Тукайның **тууына 140 ел тулуга** багышланган
**"Тукайлы яз"кичәсе**
кысаларында үтүче иҗади эшләр
район мәгариф бүлеге бәйгесе
НИГЕЗЛӘМӘСЕ

**1.Төп нигезләмә**

1.1. Иҗади эшләр район конкурсы (Конкурс) Әтнә районы мәгариф бүлегенең планы нигезендә һәм "Татарстан Республикасының дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законы", Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстанда башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан дәүләт программасын тормышка ашыру максатыннан, бөек шагыйрь Габдулла Тукайның **тууына 140 ел тулуга** тулуга багышлап эшләнә. Нигезләмә Конкурсны оештыру һәм үткәрү тәртипләрен билгели.

1.2. Конкурсны оештыручы – Әтнә районы мәгариф бүлеге

**2. Конкурсның иаксаты һәм бурычлары**

2.1. Максат: бөек шагыйрь Габдулла Тукайның иҗатына әдәби мирасына игътибарны арттыру

2.2. Бурычлар:

- әдәбият һәм сәнгатькә сәләте булган укучыларны ачыклау, аларга иҗади яктан үсүдә һәм камилләшүдә ярдәм күрсәтү;
- эстетик зәвык һәм әдәбиятка мәхәббәт тәрбияләү;
- укучыларда милли үзаң тәрбияләү, туган якка, Ватанга мәхәббәт хисе формалаштыру;
- бөек шагыйребез Габдулла Тукайның иҗатын өйрәнергә этәргеч ясау;
- укучыларның игътибарын рухи мирасыбызны өйрәнүгә юнәлтү.

**3. Конкурсның катнашучылары**

3.1. Конкурста, эш юнәлешләренә карап, районның гомуми һәм өстәмә белем бирү учреждениеләреннән 7 яшьтән 18 яшькә кадәр булган укучы балалар һәм укытучылар, педагоглар катнаша ала.

3.2. Конкурс түбәндәге яшь төркемнәре арасында үткәрелә:

- 7-10 яшьлек укучылар;

- 11-13 яшьлек укучылар;
- 14-18 яшьлек укучылар;

-укытучылар, өстәмә белем бирү педагоглары.

**4. Конкурсның эш юнәлешләре һәм куелган таләпләр**

4.1. Конкурс түбәндәге юнәлешләр буенча үткәрелә:

1. Габдулла Тукай әсәрләре буенча **инсценировка**
2. Габдулла Тукай иҗатына багышланган **кул эшләре**
3. Габдулла Тукай әсәрләре буенча **рәсемнәр**;
4. Габдулла Тукай шигырьләренә нейросеть куллану юлы белән эшләнгән **видеоролик**.

4.2. Габдулла Тукай әсәрләре буенча **инсценировка ( яшь төркемнәре чикләве юк. Инсценировкада укучылар, укытучылар, әти-әниләр бергәләп катнаша ала) -** шагыйрьнең бер яки берничә әсәрен берләштереп, әйтергә теләгән төп эчтәлектәне өзекне тамашачыга сәхнәләштереп уйнап күрсәтү. Таләпләр:

- сәхнәдә уйнау вакыты 5 минуттан артмаска тиеш
- музыкаль бизәлеш, декорация, сәхнә киеменә аерым өстәмә балл куела
- артистизм, режиссер фантазиясе, төп фикерне җиткерү алымнары осталыгына игътибар бирелә.

Инсценировканы 20 апрельгә кадәр видеога төшереп rita.sabir@mail.ru электрон почтасына җибәрергә кирәк. Видеоның сыйфатына таләпләр куелмый. Югарыда саналган таләпләргә туры килеп, сайлап алынган эшләр кичә барышында сәхнәдә чыгыш ясарга чакырыла.

4.3. Габдулла Тукай иҗатына багышланган **кул эшләре** бәйгесенә Тукай геройларын чагылдырган яки шагыйрьнең биографиясенә кагылышлы, барлык төр материалдан эшләнгән аппликацияләр, сувенир уенчыклар, аксессуарлар, тегелгән - чигелгән яки агачтан эшләнгән йорт җиһазлары күргәзмәсе. Эшләргә урыннар яшь төркемнәренә карап биреләчәк:

- 7-10 яшьлек укучылар;
- 11-13 яшьлек укучылар;
- 14-18 яшьлек укучылар;

- укытучылар, өстәмә белем бирү педагоглары

4.4. Габдулла Тукай әсәрләре буенча **рәсемнәр** А3 форматта ясала. Техникасы – ирекле (карандаш, гуашь, акварель...). Рәсемнең аскы ягына таблица формасында Рәсем исемен, авторның Исем Фамилиясен, тулы яшен, мәктәбен, җитәкчесенең фамилия һәм инициалларын языпябыштырырга (шрифт 12, Times New Roman юлара интервал – одинарный). Эшләргә урыннар яшь төркемнәренә карап биреләчәк.

- 7-10 яшьлек укучылар;
- 11-13 яшьлек укучылар;

- 14-18 яшьлек укучылар;
- укытучылар, өстәмә белем бирү педагоглары.

Рәсемнәргә урын билгеләгәндә оригинальлеккә, моңарчы китап - журналларда һәм интернетта булган рәсемнәрнең күчереп ясалмаганлыгына өстенлек биреләчәк.

4.5. Габдулла Тукай шигырьләренә нейросеть куллану юлы белән эшләнгән **видеоролик** 3 минуттан артмаска тиеш. Видеоролик башында яки ахырында автор турында барлык мәгълүмат язма титр рәвешендә күрсәтелергә тиеш:

- авторның исем фамилиясе
- мәктәбе, классы (яки тулы яше)

Эшләргә урыннар яшь төркемнәренә карап биреләчәк.

- 7-10 яшьлек укучылар;
- 11-13 яшьлек укучылар;
- 14-18 яшьлек укучылар;
- укытучылар, өстәмә белем бирү педагоглары.

Эшләргә урын билгеләгәндә видеороликта үзебезнең төбәкнең табигате, истәлекле урыннары, районыбызны танытучы билгеләрнең дә урын алуына өстенлек биреләчәк.

Видеороликларны 20 апрельгә кадәр rita.sabir@mail.ru электрон почтасына жибәрергә кирәк. Югарыда саналган таләпләргә туры килеп, сайлап алынган эшләр кичә барышында тамашачыларга күрсәтү өчен кулланылачак.

**5. Конкурсның үткәрелү вакыты**

Конкурс эшләренә заявкалар 2026 елның 2 апреленнән башлап 20 апрельгә февральгә кадәр rita.sabir@mail.ru электрон почтасына кабул ителә. Эшләрне почтага “Тукайлы яз” темасы белән салырга.

**Заявка формасы:**

| Номинация | Эшнең исеме | Автор | Мәктәбе, классы, тулы яше (укучылар өчен генә) | Житәкчесе |
|---|---|---|---|---|
| Кул эшләре | Чигүле мендәр | Галиева Галия | Күңгәр урта мәктәбе, 10 сыйныф, 16 яшь | Валиева Вәлия |

**Дипломнарда язылачак информация Заявка формасына карап алына!!!**

**6. Конкурска нәтиҗәләр һәм жюри**

1,4 номинация буенча эшләргә нәтиҗә 2026 елның 22 апрель числосында ясала.

2,3 номинация буенча эшләргә нәтиҗә 28 апрелендә "Тукайлы яз" кичәсе алдыннан ясала.

Һәр эш юнәлешендә 1,2,3 урыннар билгеләнә. Аларга Җиңүче дипломнары һәм барлык катнашучыларга Катнашучы сертификаты кичә барышында тапшырылачак.

Белешмәләр өчен элемтә: 88436921039, Рита Ришатовна